РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 29 июле** **Чистай шәһәре** **№9/1**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Чистай шәһәре
Советының «Чистай шәһәрен
төзекләндерү кагыйдәләрен раслау
турында»2013 елның 4 июнендәге
22/2 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

Чистай шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында, гамәлдәге законнар, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнары бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсе, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2013 елның 4 июнендәге 22/2 номерлы карары (Чистай муниципаль районының 2014 елның 30 апрелендәге 29/9 номерлы, 2017 елның 31 августындагы 17/8 номерлы, 2018 елның 27 июнендәге 26/1 номерлы, 2019 елның 6 февралендәге 31/7 номерлы, 2020 елның 27 маендагы 47/4 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Чистай шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. IV. ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ЭШЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕН ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ЕШЛЫГЫН ДА КЕРТЕП, ШӘҺӘР ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕН ҖЫЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ бүлегенең 183 пунктындагы 183.14 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. VI. ТӨЗЕЛЕШ, РЕМОНТ, КОММУНИКАЦИЯЛӘРНЕ РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘГӘНДӘ ҖИР ЭШЛӘРЕН БАШКАРУГА ТӨП ТАЛӘПЛӘР бүлегенең 229 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Җир эшләрен башкаруга ордер бирү турында карар кабул иткәндә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына

салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов